ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.08.2016 с. Русское Макулово 45

Макыл авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында

КАРАР БИРӘМ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары күрсәтә торган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген расларга (1 нче кушымта).

2. «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр исемлеген раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге башкарма комитетының 2013 елның 21 маендагы 61 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты
җитәкчесе: Л.Р. Цветкова

Югары Ослан муниципаль
районының Макыл авыл
җирлеге башкарма
комитетының
20.08.2016 ел № 45 карарына
1 номерлы кушымта

Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре исемлеге

| № т/б | Дәүләт хезмәтенең аталышы |
|---|---|
| 1. | Тууны дәүләт теркәве. |
| 2. | Никахлашуны дәүләт теркәвенә алу. |
| 3. | Никахны өзүне дәүләт теркәвенә алу. |
| 4. | Ата булуны билгеләүне дәүләт теркәве. |
| 5. | Үлемне дәүләт теркәве. |

Югары Ослан муниципаль районының Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты күрсәтә торган муниципаль хезмәтләр исемлеге

| № т/б | Муниципаль хезмәт исеме |
|---|---|
| 1. | Күчемсез милек объектын бирү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару. |
| 2. | Гражданга социаль наем шартнамәсе буенча муниципаль милектәге торак урын бирү. |
| 3. | Кадастр исәбенә кую максатында муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен килештерү. |
| 4. | Җир кишәрлегенә белешмә, йорт биләмәсенә белешмә, гаилә составы турында белешмә, яшәү урыныннан белешмә, хуҗалык кенәгәсеннән өземтәләр бирү. |
| 5. | Документлар күчермәләренең һәм алардан өземтәләрнең дөреслеген раслау |
| 6. | Җир кишәрлеген сайлау актын килештерү. |
| 7. | Торак урыннарын гражданнар милкенә тапшырганда документлар рәсмиләштерү |
| 8. | Җирлекнең генераль планыннан өземтә бирү |
| 9. | Васыятьнамәләрне һәм ышанычнамәләрне таныклау |

Макыл авыл җирлеге башкарма комитеты
җитәкчесе: Л.Р. Цветкова